РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**

**КАРАР**

«28» август 2025г. г. Альметьевск №72

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советы депутаты статусы турында Нигезләмә хакында» 2023 елның 11 августындагы 237 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Ачык хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

Әлмәт муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советы депутаты статусы турында Нигезләмә хакында» 2023 елның 11 августындагы 237 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2024 елның 26 июнендәге 302 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. карар преамбуласында «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законда» сүзләрен «Ачык хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында «2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законда»сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 1.2. кararга кушымтада:

а) 2 статьяның 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Әлмәт муниципаль районы Уставының 25 статьясындагы 1 өлеше нигезендә муниципаль район составына керүче җирлекләр башлыкларыннан һәм күрсәтелгән җирлекләр советлары депутатларыннан торган район Советы депутаты вәкаләтләре тиешенчә муниципаль район составына керүче җирлек башлыгы сайланган һәм үз вазыйфасына кергән көннән яисә әлеге җирлек Советы депутаты әлеге җирлек керә торган район Советы депутаты итеп сайланган көннән башлана һәм тиешенчә җирлекнең вәкиллекле органы тарафыннан җирлек башлыгын сайлау турындагы мәсьәлә карала торган яңа чакырылыш утырыш уздырылган көндә яисә район советы составына әлеге җирлектән депутат сайлау турындагы карар үз көченә кергән көннән туктатыла, моңа әлеге Нигезләмәнең 3 статьясында каралган очраклар керми.»;

б) 3 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Депутат вәкаләтләре түбәндәге очракларда вакытыннан алда туктатыла:

1) үлем;

2) үз теләге белән отставкага китү;

3) суд тарафыннан хокукка сәләтсез яисә хокукка сәләте чикләнгән дип тану;

4) суд тарафыннан хәбәрсез югалган дип танылу яисә вафат дип игълан ителү;

5) аңа карата судның гаепләү хөкеменең законлы көченә керүе;

6) даими яшәү урынына Россия Федерациясеннән читкә чыгу;

7) Россия Федерациясе гражданлыгының туктатылуы яисә чит дәүләт гражданлыгының (гражданлыгының) яисә яшәүгә рөхсәтенең яисә Россия Федерациясе гражданының чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукын раслый торган башка документының булуы;

8) район Советы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату;

9) хәрби хезмәткә чакыру яисә аны алмаштыручы альтернатив граждан хезмәтенә юллама;

10) аның җирлек башлыгы, муниципаль район составындагы җирлек Советы депутаты буларак вәкаләтләре туктатылу;

11) чит ил агенты статусын алу;

12) «Ачык хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законда һәм башка федераль законнарда билгеләнгән башка очраклар.

Депутатның вәкаләтләре муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы утырышларында җитди сәбәпләрсез депутат булмаганда алты ай рәттән район Советы карары белән вакытыннан алда туктатыла.»;

в) 5 статьяның 1 өлешендәге беренче абзацында «даими булмаган нигездә» сүзләрен «, кагыйдә буларак, даими булмаган нигездә» сүзләренә алмаштырырга»;

г) 6 статьяның 1 пунктындагы «к» пунктчасын төшереп калдырырга;

д) 12 статьяның 5 өлешендәге беренче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

е) 20 статьяның 2 өлешендә «сакланып калуы сүзен «эш бирүче тарафыннан сакланып калып эшләүдән азат ителүе» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны район Советының законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Муниципаль район Башлыгы Г.М. Хәбутдинова

«СОВЕТ АЛЬМЕТЬЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА»